Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Елховой авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

27 январь 2023 ел № 1

Әлмәт муниципаль районы Елховой авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында

«Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 январендәге 8-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Татарстан Республикасы буенча Пенсия фонды бүлегенең Әлмәт районындагы Клиент хезмәте (бүлек хокукларында) 2023 елның 24 январендәге 51-34-09/156 номерлы мөрәҗәгате нигезендә

Елховой авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. 1 нче, 2 нче кушымталар нигезендә Әлмәт муниципаль районы Елховой авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 7793,48 сум күләмендә 2023 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә һәм билгеләргә.

2. Әлмәт муниципаль районы Елховой авылы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Елховой авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында» 2022 елның 31 январендәге 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3.. Әлеге карарны Әлмәт районы, Елховой авылы, Совет урамы, 67 йорт, адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2023 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Елховой авылы
башкарма комитеты җитәкчесе А.А. Хәсәншин

Әлмәт муниципаль районы
Елховой авылы башкарма комитетының
2023 елның 27 январендәге 1 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районы Елховой авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 110,41 |
| 2 | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4474,78 |
| 3 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 695,19 |
| 4 | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2513,10 |
| Барлыгы | | 7793,48 |

Елховой авылы
башкарма комитеты җитәкчесе А.А. Хәсәншин

Әлмәт муниципаль районы
Елховой авылы башкарма комитетының
2023 елның 27 гыйнварендәге 1 номерлы
карарына 2 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районы Елховой авыл җирлеге территориясендә
җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә күрсәтелә
торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 110,41 |
| 2 | Үлгән кешенең гәүдәсен төрү | 2 623,44 |
| 3 | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1 851,34 |
| 4 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 695,19 |
| 5 | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2513,10 |
| Барлыгы | | 7793,48 |

Елховой авылы
башкарма комитеты җитәкчесе А.А. Хәсәншин

Р.06-1389/12 ЕЛХОВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ИНН 1644036400 КПП 164401001 ОГРН 10616...